| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br><br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НИЖНЕКУЮКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br><br>ул. Татарстан , д.71а, село Нижний Куюк, 422741<br>Тел.: (8-84369) 33-2-47; факс: 33-2-47 | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ТҮБӘН КӨЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ<br><br>Татарстан урамы., 71 а йорты, Түбән Көек авылы, 422741<br>Тел.: (8-84369) 33-2-47; факс: 33-2-47 |
| --- | --- | --- |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«29» гыйнвар 2021 ел. № 2

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр кыйммәтен раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль закон, 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы “Җирләү һәм җирләү эше турында” Федераль закон, 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы “Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында “Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары, 2021 елның 28 гыйнварындагы 73 нче номерлы “2021 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында” Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әтнә мунципаль районының Түбән Көек авыл җирлегендә № 1 нче һәм № 2 нче кушымта нигезендә җирләү буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелгән хезмәт бәясен 6424,98 сум күләмендә билгеләргә һәм 2021 елның 1нче февраленнән гамәлгә кертергә.
2. Түбән Көек авыл башкарма комитетының 2020 елның 31 гынварындагы 1 номерлы «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр кыйммәтен раслау турында»гы карарын 2021 елның 1 февраленнән үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе Д.М. Галиәхмәтов

Әтнә муниципаль районы Түбән Көек
авыл башкарма комитетының 2021
елнын 29 гыйнварындагы 2 нче
номерлы карарына 1 нче кушымта

2020 елның 1 февраленнән җирләү буенча гарантияләнгән
хезмәтләр бәясе исемлеге

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Табут һәм башка күмү өчен кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 4254,27 |
| 3.Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) илтү. | 513,77 |
| 4. Күмү (кабер казу һәм күмү) | 1656,94 |
| Барлыгы | 6424,98 |

Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл башкарма комитетының 2021 елнын 29 гыйнварындагы 2 нче номерлы карарына 2 нче кушымта

2021 елның 1 февраленнән җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр бәясе исемлеге

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 231,19 |
| 3. Табут һәм башка күмү өчен кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 4023,08 |
| 4. Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) илтү. | 513,77 |
| 5. Күмү (кабер казу һәм күмү) | 1656,94 |
| Барлыгы | 6424,98 |